**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**2022 елның 15 декабре** **№ 153**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 15 пункты, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлеше, муниципаль берәмлек уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нурлат муниципаль районы Советының 2012 елның 19 декабрендәге 200 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына аларга карата генераль планнарны әзерләү кирәклеге булмау турында карарлар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә (2013 елның 10 сентябрендәге 256 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы 210 номерлы, 21.05.2020 № 281 карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак - коммуналь хуҗалык, эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә..

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин